КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 декабрь г.Казань № 1200

Стационар шартларда ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга медицина ярдәме күрсәткәндә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләренең һәм ирекле булып йөрүчеләрнең (волонтерларның) алар белән медицина оешмасында бергә булуын оештыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеге турындагы һәм аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның урнашуы турындагы нигезләмәнең 51 пунктындагы «ш$^1$» пунктчасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Стационар шартларда ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга медицина ярдәме күрсәткәндә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләренең һәм ирекле булып йөрүчеләрнең (волонтерларның) алар белән медицина оешмасында бергә булуын оештыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 8 декабрь, 1200 нче
карары белән расланды

Стационар шартларда ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга медицина ярдәме күрсәткәндә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләренең һәм ирекле булып йөрүчеләрнең (волонтерларның) алар белән медицина оешмасында бергә булуын оештыру
тәртибе

1. Бу Тәртип «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеге һәм аларга ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеге турындагы һәм аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар урнашуы турындагы нигезләмәнең 51 пунктындагы «ш$^1$» пунктчасын гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән һәм медицина ярдәме күрсәтелгән барлык чор дәвамында стационар шартларда ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга медицина ярдәме күрсәткәндә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар хезмәткәрләренең, шулай ук дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләренең һәм ирекле булып йөрүчеләрнең (волонтерларның) алар белән (алга таба – тәрбияләнүче) медицина оешмасында бергә булуы (алга таба – даими булышлык күрсәтеп тору) кагыйдәләрен билгели.

2. Бу Тәртипне тормышка ашыруда түбәндәгеләр катнаша:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар (алга таба – ятим балалар өчен оешма);

медицина оешмалары;

дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган (шул исәптән иҗтимагый һәм дини) оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләре;

ирекле булып йөрүчеләр (волонтерлар).

3. Тәрбияләнүчеләрне стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтү өчен аларга даими булышлык күрсәтеп торучы зат белән бергә медицина оешмасына госпитальләштерү законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Тәрбияләнүчегә стационар шартларда медицина ярдәме күрсәткәндә медицина оешмасында ятим балалар өчен оешма хезмәткәренең тәрбияләнүче белән бергә булуы, эпидемиологик хәлне исәпкә алып, медицина оешмасының локаль норматив актлары белән җайга салына һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министр-

лыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыклары, методик тәкъдимнамәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Медицина оешмасында стационар шартларда дүрт яше тулганга кадәр бала белән, ә медицина билгеләре булганда аннан зуррак яшьтәге бала белән бергә булганда, стационар шартларда булу шартларын оештырган өчен, шул исәптән йокы урыны һәм ашарга биргән өчен даими булышлык күрсәтеп йөрүче заттан түләү алынмый.

6. Дәвалану чорында ятим балалар өчен оешма тәрбияләнүчене алмаш кием, шәхси гигиена чаралары җыелмасы, кирәк булганда, памперслар белән тәэмин итә.

7. Әгәр дә тәрбияләнүченең яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыруына шик булса яки яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыруына расланган диагнозы булса, ятим балалар өчен оешманың боерыгы нигезендә хезмәткәрләрнең берсе даими булышлык күрсәтеп торучы зат буларак билгеләнә, ул тәрбияләнүчене медицина оешмасыннан чыгарылган көннән обсервация режимында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыклары, методик тәкъдимнамәләре нигезендә карап тора.

8. Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү өчен тәрбияләнүче Россия Федерациясенең башка субъектларында урнашкан медицина оешмасына җибәрелгәндә, хезмәткәрләрнең берсе ятим балалар өчен оешма боерыгы нигезендә даими булышлык күрсәтеп торучы зат буларак билгеләнә, ул дәвалану урынына барганда һәм аннан кайтканда, шулай ук госпитализацияләнгән вакыт дәвамында даими булышлык күрсәтеп торуны гамәлгә ашыра.

9. Ятим балалар өчен оешмалар тәрбияләнүчеләре белән бергә булуны оештыру өчен медицина оешмасы, ятим балалар өчен оешма һәм дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган (шул исәптән иҗтимагый һәм дини) оешмалар, хәйрия фондлары, шулай ук гражданнар – ирекле булып йөрүчеләр (волонтерлар) арасында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән уртак боерыгы нигезендә расланган форма буенча төзелә торган хезмәттәшлек турында өчьяклы шартнамә (алга таба – шартнамә) буенча дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган (шул исәптән иҗтимагый һәм дини) оешмалар, хәйрия фондлары, шулай ук гражданнар – ирекле булып йөрүчеләр (волонтерлар) җәлеп ителергә мөмкин.

10. Дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларны, хәйрия фондларын, шулай ук аерым гражданнар-ирекле булып йөрүчеләрне (волонтерларны) җәлеп итү «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекле булып йөрү (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ятим балалар өчен оешма да, коммерциячел булмаган оешма, хәйрия фонды, ирекле булып йөрүче (волонтер) дә үзара хезмәттәшлек итүнең инициаторы булырга мөмкин.

11. Дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган (шул исәптән иҗтимагый һәм дини) оешмалар, хәйрия фондлары вәкилләре, гражданнар-ирекле булып йөрүчеләр (волонтерлар) тарафыннан тәрбияләнүчеләргә даими булышлык күрсәтеп тору түләүсез гамәлгә ашырыла һәм тәрбияләнүчеләргә мәгълүмат бирү, консультация,

психологик, аң-белем бирү, ял итү ярдәме һәм башка төрле ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт:

ял итү чараларын оештыру (аралашу, тәрбияләнүчеләргә эмоциональ ярдәм күрсәтү; бүлмәдә һәм саф һавада уеннар уйнау; иҗади дәресләр, очрашулар үткәрү; театральләштерелгән тамашалар кую; бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү; изотерапия сеансларын үткәрү; музыкаль терапия сеансларын үткәрү; видео- һәм кинофильмнар күрсәтү; тәрбияләнүчеләр белән бергә хастаханә газеталарын һәм журналларын чыгару; китапларны кычкырып уку, тәрбияләнүчеләрнең буш вакытын башка төрле оештыру һәм күңел ачу чаралары);

белем бирү чараларын оештыру (лекцияләр үткәрү; компьютер белеме буенча дәресләр үткәрү; гомуми белем бирә торган мәгариф программасын, урта һөнәри белем бирә торган мәгариф программасын үзләштерүдә ярдәм итү; өстәмә белем алуда ярдәм итү; белем бирү эшчәнлегенең башка төрләре);

тормышта авыр хәлдә калган тәрбияләнүчеләр белән аралашу һәм аларга мораль ярдәм күрсәтү;

тәрбияләнүчеләр белән иҗади дәресләр үткәрү;

тәрбияләнүчеләргә көнкүреш ярдәме күрсәтү (бүлмәне чиста тоту, кирәкле продуктлар, әйберләр сатып алу, ашаганда, киенгәндә ярдәм итү, медицина процедураларына озата бару, санитария-гигиена хезмәте күрсәтү).